Казан шәһәре Идел буе районының
«5 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы»
мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе



# 4-7 яшьлек балалар белән шәхси эшчәнлек вакытында лексик минимумны ныгыту өчен методик тәкъдим

Казань, 2020 г.

Методик тәкъдимдә 4-7 яшьлек балалар белән шәхси эшне оештыру УМК «Татарча сөйләшәбез» (Зарипова З.М.) кысаларында лексик минимумны ныгыту күрсәтелгән. Төп нигезе итеп Т.Н.Новикова-Иванцованың начар сөйләшүче балалар белән эш алымы кулланылган. Шулай ук , эшне оештыруда документ үрнәкләре тәкъдим ителә.

Бу тәкъдимнәр балалар бакчасында татар теле өйрәтүче тәрбиячеләр, группа тәрбиячеләре өчен бирелә. Шулай ук балаларының ике дәүләт телен белүендә кызыксынган ата-аналар да кулланырга мөмкин.

Әлеге эш тәртибе хәзерге вакытта Казан шәһәре Идел буе районында урнашкан « 5 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениясендә (филиал) гамәлгә ашырыла.

**4-7 яшьлек балалар белән шәхси эшчәнлек вакытында лексик минимумны ныгыту өчен методик тәкъдим.**

**Аңлатма.**

Билгеле булганча, һәр бала үзенчәлекле. Ул нерв системасы, психик һәм физик үсеш ягыннан үзенчәлекле. Баланың шәхси үзенчәлекләре- үзләштерү күнекмәләренә, тирә-як мөнәсәбәтенә зур йогынты ясый. Бигрәк тә, балалар бакчасына авыру сәбәпле бик сирәк йөргән, «көчсез», тыйнак, әкрен, оялчан балалар зур игътибар белән кузәтелергә тиеш.

Әгәр ФГОС куйган таләпләрне анализлаган вакытта, шәхси эшне балалар бакчасында төп укыту программасы кысалары ярдәмендә тормышка ашыру өчен түбәндәге шартлар үтәлергә тиеш:

**психолого-педагогик шартлар** - баланың шәхси үзенчәлекләрен– төрле психологик характеристикаларына, мәгълүматны үзләштерүенә, аңлавына карап исәпкә алу.

**Кадр шартлар**- тәрбияче башка белгечләр белән үзара бәйләнештә тагын да югары нәтиҗәләр китерә.

**Матди-техник шартлар**- төркемне ата-аналар ярдәмендә җиһазлау.

**Әйләнә-тирәне үстерү өчен таләпләр**- бөтен төркем белән шәхси эшне башкарган вакытта әйләнә тирәне тулыландыру өчен түбәндәге принциплар исәпкә алына: куркынычсызлык, алмашучанлык, хәрәкәтләндерү һәм педагогик функциональлек.

Балалар бакчасында шәхси эшне оештыруда иң зур ярдәмче булып- дидактик уеннар тора. Алар ярдәмендә балалар лексик минимумны үзләштерәләр һәм сөйләм телен тулыландыралар.

Дидактик уеннар балалар арасында мөстәкыйль һәм уртак эш буларак оештырыла. Уен барышында алар үз теләкләрен белдереп бер үзе , дуслары яки зур булмаган төркемнәр белән уйнарга мөмкин. Мөстәкыйль уеннар ярдәмендә баланың белем дәрәҗәсен, уйнау сәләтен, акыл үсешен һәм үз-үзенең тотышын күзәтергә мөмкин. Бу күзәтү вакытында тәрбияче баланың нинди тема буенча белеме начар булуы яки киресенчә яхшы үзләштерүне аңлый ала. Бу алым, укытучыга, бала нинди тема буенча калыша, нинди яктан көчле һәм нинди уеннар файдалы булуын күрсәтә.

Тәрбияче оештырган шәхси уеннарда бала белән тәрбияче арасындагы бәйләнеш уңай шартлар булдыра. Бу вакытты, тәрбияче баланың ни өчен, калышуының тирән сәбәпләрен ачыкларга тырыша һәм тагын да ныгытып балага актив күнегүләр ярдәмендә булыша башлый.

Педагоглар шәхси эшне оештыру вакытында күп кыенлыкларга очрыйлар, чөнки алар бу эшне дөрес итеп оештыруны кузалламыйлар: ничек дөрес итеп эшне оештырырга, ничек нәтиҗәне күзәтергә, ничек группа тәрбиячеләре белән

бәйләнешне оештырырга. Мин дә шул ук кыенлыклар белән очраштым. Логопед дәресләрендәге күзәтүләр миңа бу кыенлыклардан чыгарга ярдәм итте. Ул да, шул ук балалар белән, яңа сүзләр өстендә эш итә иде. Асылда, без аның белән икебез дә бер үк төркемдә һәм бер үк балалар белән эшлибез, ә нишләп әле мин аның начар сөйләшүче балалар белән нәтиҗәле эш тәҗрибәсе белән кулланмыйм ( Т.Н. Новикова-Иванцова). Бу эш баланың сөйләм үстерешенә генә түгел, ә мәктәпкә әзерләргә ярдәм итәчәк.

Шуңа күрә, әлеге методик тәкъдимдә, мин күптапкыр кабатлау нигезендә яңа сүзләрне үзләштерү, ике-өч сүздән торган сүзтезмәләр төзү һәм сөйләмдә куллану өчен, төрле методик һәм лексик материал тупларга тырыштым.

Укытучы–логопед кебек мин дә түбәндәге эш төрләрен кулланырга тырышам:

- иҗек өстендә эш,
- сүзлек эше: исем, сыйфат һәм фигыль сүзләре, - сүзтезмә өстендә эшләү.

Методик эш сүзләрне һәм сүзтезмәләрне төрле хәлләрдә күптапкыр кабатлауга таяна; шунлыктан аңлау, ачыклау, киңәйтү- сүз байлыгын камилләштерүгә китерә.

**Методик тәкъдимнең максаты**: татар теленнән яшь белгечләргә шәхси эшне оештыруда ярдәм иту.

**Нәтиҗә**:

- татар телен үзләштерү сыйфатын арттыру,
- баланың үзенчәлекләрен исәпкә алып, татар телен начар үзләштергән балаларга шәхси ярдәм итү,
- татар теле өйрәтүче тәрбияче белән группа тәрбиячесе арасында элемтә билгеләү.
- ата-аналарны лексик минимумны ныгытуда җәлеп итү.

**Эшнең яңалыгы-** логопед начар сөйләшүче балалар белән кулланган эшчәнлекне, «Татарча сөйләшәбез» ( автор Зарипова З.М) дигән укыту методик комплектының лексик минимумны өйрәтүдә яраклаштырып төзелә.

**Балалар белән иҗек өстендә эш**.

**«Йозак» уены**

**<u>Максат</u>:** яңа сүзне өйрәнү яки ныгыту.

**Уен кагыйдәләре:** сүзне әйткәндә бала иҗекләрне чәбәкли.

**Инструкция** (тәрбияче белән эшләнә): ике уч түбен кушабыз (рәс.1.), икесен төрле якка 90 градуска борабыз (рәс.2.) һәм баш бармаклар белән «йозакны ябабыз» (рәс.3.).

Хәзер мин сүзне әйтәм һәм чәбәк итеп, «йозакны» ачам һәм борам. Игътибар белән кара һәм тыңла. ( Тәрбияче эшләү гамәлен күрсәтә. Башта уң кул өстә (рәс.3.), аннары сул кул (рәс.4.)). Ә хәзер син эшләп кара.

*Искәрмә:басымсыз иҗеккә әкрен кагабыз, ә инде басымлы иҗеккә каты итеп.*


Рәс.1.


рәс.2.


рәс.3.


рәс.4.

**Сүз өстендә эш.**
**Исем һәм сыйфат сүзләре.**


**«Төймә» уены.**


**<u>Максат:</u>** «Татарча сөйләшәбез» укыту-методик комплектының «Минем өем», «Уйный-уйный үсәбез», «Без инде хәзер зурлар- мәктәпкә илтә юллар» проектлары буенча, лексик минимумны туплау һәм активлаштыру.

**Уен кагыйдәләре**:тәрәзәгә рәсем куела, бала рәсемне әйтә һәм шул ук вакытта бармаклары белән төсле төймәгә баса, яңадан шул ук рәсемне кабатлый һәм икенче төймәгә баса-шулай итеп барлык төймәләргә басып чыга.

Эш барышында карточкалар кулланабыз.

*бер сүзне ныгыту өчен* *ике сүзне ныгыту өчен*






Рәс.5 Рәс.6

**Инструкция:** хәзер без синең белән рәсемдә сүрәтләнгән сүзне әйтәбез һәм шул ук вакытта рәсем астындагы төсле төймәләргә басабыз (рәс.5.). Тик йодрыкны без дөрес итеп тотарга тиеш: 5 бармакны йодрык эченә яшерәбез, ә хәзер баш, имән бармакларны чыгарабыз. Сүз әйтелә һәм баш бармак белән төймәгә басабыз, шул ук сүзне икенче тапкыр кабатлаганда имән бармак белән икенче төймәгә басабыз (рәс.7-9). Шулай итеп төймәләр беткәнче эшлибез.








Рәс. 7. Рәс.8. Рәс.9.

*Искәрмә: баш һәм имән бармаклар гына эшли.*

Ике сүзне өйрәнгәннән соң яки ныгытканнан соң башка схема (рәс.6.) тәкъдим итәбез. Бу схема белән без берьюлы ике сүзне ныгыта алабыз. Шулай ук төймәләр белән эшлибез, тик хәзер ике сүзне бер-бер артлы кабатлыйбыз.

Төркемнәр белән эшләгән вакытта, карточканы тактага элеп куярга була, ә балаларга төймә өлешен генә таратырга (рәс.10). Бу вакытты тәрбиячегә дидактик материалны әзерләү җиңелəя.



Рәс.10. Рәс.11.



Шуннан, балалар билгеле бер тема буенча лексик минимумны үзләштергәннән соң һәрбер балага түбәндәге карта (темалар буенча) тәкъдим итеlә (рәс.11).

**Инструкция** : Малай кая, күрсәт? Сүрәтне фишка белән ябып куй. Кыз кая? Сүрәтне фишка белән ябып куй. Балалар сүрәтне күрсәтәләр һәм фишка белән ябалар (түгәрәк яки шакмак). Әгәрдә бала авырсына икән, өлкән кеше аңа булыша. Барлык сүрәтләрне ябып бетергәннән соң инструкция алмашына.

**Инструкция**: Малай (кыз) ясалган сүрәтне ач.

Бала бер үзе яки өлкән кеше ярдәмендә бер-бер артлы сүрәтләрне ача. Башта бу биремнәр бер тәртиптә эшләнә: сулдан-уңга, өстән-аска таба. Соңыннан сүрәтләрне табу, ябу һәм ачу тәртибе үзгәрә. Бала, игътибар белән укытучы әйткән инструкцияләрне тыңларга, аңларга тиеш. Шулай ук, һәрбер сүзне кычкырып яки тыныч кына әйтергә тәкъдим итергә була.

Киләсе эш- бармаклар белән. Шулай ук, бөтен 5 бармак та йодрыкта. Бала, рәсемне атый бара һәм бармак белән төймәләргә баса, тик бу юлы 5 бармак та эшли.

**Фигыль сүзлеге өстендә эш.**

**Максат**: «Татарча сөйләшәбез» укыту-методик комплектының «Минем өем», «Уйный-уйный үсәбез», «Без инде хәзер зурлар- мәктәпкә илтә юллар» проектларында бирелгән фигыль сүзлеген активлаштыру һәм туплау.

Шулай ук, югарыда әйтелгән алымнарны карточкалар (рәс.5,6,17) ярдәмендә кулланабыз.



Рәс .17.

**Сүзтезмә өстендә эш.**


**Максат:** сүзтезмә формуласын ныгыту.

Әлеге эш стадиясендә, сүзтезмә өстендәге эшне билгеле бер яшь төркемендә лексик минимумга кергән фигыльләр генә бирелә.

Башта һәр фигыль өйрәнелгән исем белән үзләштерелә.

**«Кем нишли?» уены.**


**Уен кагыйдәләре**. Бала стрелка буенча рәсемне пиктограмма белән тоташтыра, ә соңыннан кем- нишли икәнен әйтә (рәс.18.).



Рәс.18.

Әлеге уенда, сүзтезмәне дөрес  әйтү генә тугель, ә аны аңлавы да формалаштырыла.

Бөтен сүрәт әйтелгәннән соң, укытучы түбәндәге инструкцияне бирә «Малай утыра. Күрсәт» (рәс.19.). Шул ук тәртиптә башка фигыльләр дә өйрәнелә.



Рәс.19.

Фигыльләрне үзләштергәннән соң - бер персонаж белән башкарылган төрле гамәлләр күрсәтелгән карточка бирелә: «Малай укый» «Малай ашый»…

Шулай ук, югарыда әйтелгән  алымнарны кулланабыз. Балалар билгеле бер тәртипкә ияләшергә, механик рәвештә рәсемне күрсәтергә һәм сүзтезмәне әйтергә тиеш тугел. Алар олылар әйткән сүзгә- игътибарлы булып кәгазь битендә ориентлашырга һәм билгеле бер рәсемне табырга тиеш.

**Шәхси эшне оештыру буенча тәкъдимнәр**.

Бер гамәлне өйрәнү өчен дәрес саны- баланың үзләштерүенә карап үткәрелә. Башта күп вакыт таләп ителсә, соңыннан үзләштерү тизерәк барачак. Тик, бер дәрескә бер дән артык гамәл алырга ярамый. Бала бик авыр үзләштерергә мөмкин. Бер дә борчылмагыз. Истә тотыгыз: сабырлык һәм хезмәт һәрвакытта билгеле бер нәтиҗәгә китерә.

Үткәннәрне кабатлаган вакытта балаларга уйлау, тыңлау, күрү сәләтләрен тагын да үстерү өчен өстәмә сораулар да бирергә мөмкин. Мәсьәлән: «күрсәт, әйт, кем бара, кем утыра?». Бу материалны шәхси дәресләрдә генә түгел, ә ярты төркем белән эшләгәндә дә кулланырга мөмкин.

Балалар материалны җиңел үзләштерү өчен, өлкәннәр сөйләменә билгеле бер таләпләр куела:

- Сөйләм темпы тиз булырга тиеш түгел, ашыкмыйча гына сөйләргә .
- Сузык һәм тартык авазларны тулы итеп сөйләргә, басымлы сузыкларны- сузырга.
- Инструкция дөрес, ачык, кыска , балага аңлаешлы булырга тиеш.
- Сүзтезмәдәге сүзләр бер сулауда ,бергә әйтелергә тиеш.
- Балага эндәшү, инструкция, гамәлләр башкару вакытында паузалар кирәк. Бөтен бала да инструкцияне тиз аңламый, аларга аңлау һәм үтәү өчен вакыт кирәк.

Кушымта № 1

Лексик минимумны авырдан үзләштергән балалар белән эшләү тәртибе (алгоритм)

| № | Педагогның эш эчтәлеге | | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | Үткән темадан соң йомгаклау дәресләре үткәрү. | | |
| 2 | Билгеле бер тема буеча кыенлыклар белән очрашкан балаларны ачыклау. | | |
| 3 | Кынлыклар сәбәпләрен билгеләү. | | |
| 4 | Билгеле бер теманы начар үзләштерүче балаларга шәхси эшне төзү. | | |
| 5 | Балалар белән шәхси эшне, алдан төзелгән эш тәртибе буенча үткәрү. | | |
| 6 | Бала өчен йомгаклау дәресен кабат үткәрү. | | |
| 7 | Баланың шәхси эш картасында нәтиҗәне теркәү. | | |

Кушымта № 2

Кыенлыклар картасы (2020-2021 г.г.)

Баланың И.Ф. ________________________________________

Төркем № ___ Лексик

тема «Гаилә»

| | Кулланыла торган методлар | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|
| Дөрес күрсәтә һәм әйтә. | *Кулланыла торган дидактик уеннар* | |
| Әни | “Йозак” уены<br>“Төймә” уены<br>“Минем гаилә” режиссер уен. | *Кулдан шәхси эшне үткәрү вакытын язабыз.* |
| Әти | | |
| Әби | | |
| Бабай | | |
| Малай | | |
| Кыз | | |
| | | |

## Лексик тема: “Чиста, пычрак”

| | Кулланыла торган методлар | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|
| Дөрес күрсәтә һәм әйтә. | *Кулланыла торган дидактик уеннар* | |
| Чиста | “Йозак” уены<br>“Төймә” уены<br>“Минем гаилә” режиссер уен. | *Кулдан шәхси эшне үткәрү вакытын язабыз.* |
| Пычрак | | |

## Лексик тема: “Яшелчәләр”

| | Кулланыла торган методлар | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|
| Дөрес күрсәтә һәм әйтә. | *Кулланыла торган дидактик уеннар* | |
| Кишер | “Йозак” уены<br>“Төймә” уены<br>“Минем гаилә” режиссер уен. | *Кулдан шәхси эшне үткәрү вакытын язабыз.* |
| Суган | | |
| Бәрәңге | | |
| Кыяр | | |
| Кәбестә | | |
| Шалкан | | |

## Фигыль

| | Кулланыла торган методлар | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|
| Дөрес күрсәтә һәм әйтә. | *Кулланыла торган дидактик уеннар* | |
| Йоклый | “Йозак” уены<br>“Төймә” уены<br>“Минем гаилә” режиссер уен. | *Кулдан шәхси эшне үткәрү вакытын язабыз.* |
| Ашый | | |
| Эчә | | |
| Утыра | | |
| Йөгерә | | |
| Җырлый | | |
| Бии | | |

№ __.зурлар төркемендә шәхси эшне үткәрү графигы .

| № | Баланың И.Ф | СЕНТЯБРЬ 2020ел | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 атна | | | | 2 атна | | | | | 3 атна | | | | | 4 атна | | | | | 5 атна | | |
| 1 | | 1.09 | 2.09 | 3.09 | 4.09 | 7.09 | 8.09 | 9.09 | 10.09 | 11.09 | 14.09 | 15.09 | 16.09 | 17.09 | 18.09 | 21.09 | 22.09 | 23.09 | 24.09 | 25.09 | 28.09 | 29.09 | 30.09 |
| 2 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Татар теле тәрбиячесе белән төркем тәрбиячесе арасындагы үзара бәйләнешне теркәү кәгазе.

*Проект «……….», тема « ………»*

Для успешного закрепления в активном словаре лексического минимума по УМК «Говорим по-татарски» прошу вас обращать внимание на употребление следующих слов и фраз в разговорной речи следующими детьми:

УМК ның “Татарча сөйләшәбез” лексик минимумны сөйләмдә уңышлы ныгыту өчен, игътибар белән түбәндәге балалар белән сүзләргә һәм сүзтезмәләргә басым ясарга:

| **№** | **Фамилия, исем** | **Ныгыту өчен сүзләр һәм сүзтезмәләр** | **Тәкъдим ителә торган күнегүләр һәм уеннар** |
|---|---|---|---|
| 1 | | | |
| 2 | | | |
| 3 | | | |
| 4 | | | |
| 5 | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 | | | |
| 7 | | | |
| 8 | | | |